РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с. Тюлячи КАРАР

«29» декабря 2025ел № 185

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 545 номерлы карары белән расланган «2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы "Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 545 номерлы карары белән расланган «2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасына (13.12.2022 № 270, от 14.12.2023 № 188, от 15.04.2025 № 60 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2021-2027 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы аталышын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә: «2021-2028 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау».

1.2. Программа Паспортында программа исеме юлын түбәндәгечә үзгәртергә:

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | Муниципаль программа «2021-2028 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» (алга таба - Программа) |

1.3. Программа Паспортында Программаны тормышка ашыру вакыты юлларын түбәндәгечә үзгәртергә:

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру вакыты | Программаны тормышка ашыру 2021-2028 еллар дәвамында башкарылачак |

1.4. Программа паспортының финанслау юлын түбәндәгечә бирергә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау | - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле бюджетының билгеләнгән тәртиптә билгеләнә һәм бүлеп бирелә торган акчалары;<br>- җирле бюджет акчаларын җәлеп итүгә күздә тотыла торган чаралар, бюджеттан тыш чыганаклар.<br>Программаны финанслау күләме тәшкил итәчәк:<br>- 2021 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2022 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2023 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2024 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2025 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2026 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2027 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2028 елда - 6,5 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш.<br>Федераль, республика бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар күләме ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |

1.5. «2021-2028 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» программасы чараларын кушымтага ярашлы рәвештә аңлатырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 9 декабрендәге
545 номерлы карарына кушымта
(2025 елның «29» 12 № 285
карарлары редакциясендә)

## Программаның чаралары
## «2021-2028 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау»

| Төп чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | | Финанслау (мең сум) (ел саен) | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 (база) ел | 2021-2023 | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2021-2027 еллар | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| **Максат: Теләче муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицинага карамаган куллану масштабларының кимету** | | | | | | | | | | | | |
| **1 бурыч. Хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен арттыру** | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләрне ачыклауга, булдырмый калуга һәм ачуга юнәлдерелгән оператив-эзләү чаралары үткәрергә | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 2021-2028 еллар | Тикшерелгән авыр һәм аеруча авыр наркоҗинаятьләрнең саны арту, процентларда | 100 | 100,1 | 100,2 | 100,3 | 100,3 | 100,3 | 100,3 | 100,3 | 100,3 |
| 1.2. Наркотикларның яңа төрләрен, шулай ук медицинадан тыш куллану өчен кулланыла торган контрольсез психоактив чаралар һәм матдәләр әйләнешен чикләү эшчәнлеген гамәлгә | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча), | 2021-2028 еллар | Ачыкланган очраклар саны | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ашыру; "Интернет" челтәрендә наркотиклар турында мәгълүмат тарату һәм наркотикларны пропагандалау буенча җәмәгать контролен оештыру | Саба һәм Теләче районнары буенча Роспотребнадзор (килешү буенча) | | | | | | | | | | | |
| 1.3. Кыргый үсә торган һәм культивацияләнә торган наркотик үсемлекләрнең үсү урыннарын ачыклау һәм бетерү буенча оператив-профилактик чаралар комплексын гамәлгә ашыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча), АҖ башлыклары (килешү буенча) | 2021-2028 еллар | Наркотиклы үсемлекләр үсешенең ачыкланган учаклары саны арту | 3 | 4 | 5 | 6 | 6 | 6 | 6 | 6 | 6 |
| 1.4. «Интернет» челтәре мөмкинлекләреннән киңрәк файдаланып, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча кабул ителгән ышаныч телефоннарының, кабул итү бүлмәләренең эш нәтиҗәлелеген һәм үтемлелеген арттырырга | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча), АҖ башлыклары (килешү буенча) | 2021-2028 еллар | Телефон аша килгән мөрәҗәгатьләр саны | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| **2 бурыч. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга уңай караш һәм наркотиклар куллануга тискәре караш булдыру** | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Мәгариф учреждениеләрендә профилактик эшне оештырырга, шул исәптән үткәрергә: Республика антинаркотик акцияләре: «Үлем белән сәүдә иткән урынны хәбәр ит!», «Наркотикларсыз тормыш», «Әзер бул! Юк, дип әйт!», «Тәмәке тартусыз Россия» | МКУ "Мәгариф бүлеге"<br>ЯЭСһТБ<br>«Олимп» яшьләр үзәге<br>МБУ «ФОРПОСТ» | 2021-2028 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 8 | 10 | 12 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14<br>-<br>3,5<br>3 |
| 2.2. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия белән үзара хезмәттәшлекне оештыру | Районның наркотикларга каршы комиссиясе | 2021-2028 еллар | Бер елга уртак утырышлар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| 2.3. Авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшүсмерләр белән | МКУ "Мәгариф бүлеге", белем | 2021-2028 | Елына чаралар саны, | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшләр башкару, шул исәптән профилактик проектларны гамәлгә ашыру аша | бирү оешмалары | еллар | берәмлекләр | | | | | | | | | |
| 2.4. Мәгариф учреждениеләрендә укучыларның ата-аналары белән наркотикларга каршы профилактик эш алып бару ("Уңышка юл" проекты) | МКУ "Мәгариф бүлеге", белем бирү оешмалары | 2021-2028 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 |
| 2.5. Районның гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларны медицина тикшерүләре үткәрүне дә кертеп, наркотик матдәләр һәм психотропик матдәләр кулланучыларны иртә ачыклау системасын үстерү | МКУ "Мәгариф бүлеге", белем бирү оешмалары | 2021-2028 еллар | Һөнәри тикшерүләр белән шөгыльләнүче укучылар саны, кеше. | - | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 |
| 2.6. Халыкка наркологик ярдәм күрсәтүче сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен наркоманнарны ачыклау, дәвалау һәм реабилитацияләү өчен медицина җиһазлары сатып алу | ДАССУ "Теләче үзәк район хастаханәсе" | 2021-2028 еллар | Экспресс-тестлар сатып алу санын арттыру, берәмлекләр | 130 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 2.7. Наркотикларга бәйле кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән аларда дәвалауга мотивация формалаштыру | ДАССУ "Теләче үзәк район хастаханәсе" | 2021-2028 еллар | Наркотикларга бәйле кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча |
| 2.8. Яшьләрнең күпләп ял итү урыннарында наркотикларга каршы эшчәнлек | ЯЭҺТБ | 2021-2028 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | кысаларында |
| 2.9. Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру буенча массакүләм мәгълүмат чаралары эшен дәвам итәргә | «Татмедиа» ААҖ филиалы (килешү буенча) | 2021-2028 еллар | Бер ел эчендә публикацияләр саны, берәмлекләр | 82 | 85 | 87 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча |
| **3 бурыч. Балаларны һәм яшьләрне кызыксынулары буенча түгәрәкләрдә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү** | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Балаларда һәм яшүсмерләрдә шәхси, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне аңлауны стимуллаштыруга юнәлтелгән методикаларны кертү ("Мөстәкыйль балалар" проектын гамәлгә ашыру) | МКУ " Мәгариф бүлеге" | 2021-2028 еллар | «Самостоятельные дети» проектында катнашкан балалар һәм яшүсмерләр саны | 58 | 58 | 60 | 65 | 65 | 65 | 65 | 65 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча |
| 3.2. Халыкның барлык категорияләре арасында күпсанлы физкультура-спорт ярышлары үткәрү:<br>- кышкы Спартакиада;<br>- Спорт һәм сәламәтлек декадасы;<br>-Чаңгычы көне;<br>- көзге кросс;<br>-май чабышы;<br>- җәйге Спартакиада | ЯЭСhТБ | 2021-2028 еллар | Халык саны, кеше | 198 | 210 | 215 | 220 | 220 | 220 | 220 | 220 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 3.3. Балаларны һәм үсмерләрне "Теләче" спорт мәктәбе, "Юность" спорт мәктәбе һәм Балалар сәламәтләндерү-мәгариф үзәге спорт түгәрәкләренә һәм секцияләренә җәлеп итү буенча мәгълүмати-аңлату эшләре алып | «Теләче» СМ, «Юность» СМ, БСМҮ | 2021-2028 еллар | Елга мәгълүмати-аңлату чаралары саны, берәмлекләр | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенч |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бару | | | | | | | | | | | | а |
| 3.4. Халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау проблемалары буенча конференцияләр, "түгәрәк өстәлләр" утырышлары, семинарлар оештыру | ЯЭСhТБ, МКУ "Мәгариф бүлеге" | 2021-2028 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 1 | 2 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| **4 бурыч. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү** | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. Районда наркотиклар вәзгыятен мониторинглауны оештыру | Наркотикларга каршы комиссия | 2021-2028 еллар | Наркотикларга каршы комиссия утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча |
| 4.2. Яшьләр сәясәте белгечләре өчен наркотикларга каршы һәм профилактик эш буенча квалификацияне күтәрү курсларында катнашу | ЯЭСhТБ, МБУ «Олимп» яшьләр үзәге, МБУ «ФОРПОСТ», МКУ «Мәгариф бүлеге» | 2021-2028 еллар (билгеләнү буенча) | Квалификация күтәрү курслары узучылар саны | 0 | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау буенча |
| 4.3. Район яшьләре арасында социологик тикшеренүләр үткәрүне оештыру | ЯЭСhТБ, МБУ «Олимп» ЯҮ, МБУ «ФОРПОСТ» | 2021-2028 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | - |
| 4.4. Наркотикларга каршы юнәлештәге мәгълүматны җирле Интернет ресурсларында бастыру | МБУ «ФОРПОСТ» | 2021-2028 еллар | Елга публикацияләр саны, берәмлекләр | 4 | 6 | 7 | 8 | 8 | 8 | 8 | 8 | Мөрәҗәгать итү яки ачыклау |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | буенча |
| 4.5. Район китапханәләрен наркотикларга каршы әдәбият белән тәэмин итү һәм аларда тематик күргәзмәләр оештыру | Мәдәният бүлеге | 2021-2028 еллар | Елына китап күргәзмәләре саны, берәмлекләр | 16 | 18 | 20 | 22 | 22 | 22 | 22 | 22 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 4.6. Наркотиклар куллануны кисәтү буенча методик әдәбият һәм күрсәтмә агитация чараларын эшләргә, бастырырга һәм таратырга | Мәдәният бүлеге | 2021-2028 еллар | Тарату материаллары, берәмлекләр | 50 | 70 | 80 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |